Зәки Нури



# Әй яңгыр килсен иде...

Бәясе 7 тиен

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1962

Бу кечкенә генә китап балаларны җәйге көннең матурлыгына сокланырга өйрәтә. Аларны чиста йөрергә, олыларның сүзен тыңларга өнди.



Зәки Нури

# Әй яңгыр килсен иде...

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1962

БИБЛИОТЕКА
ТАТКНИГОИЗДАТА
Инв. № 6335



Минем бер күлмәгем ап-ак.
Әнием теген бирде.
— Йөрмә, кызым, пычрак таптап,
Буялып, җебеп,— диде.





Менә йөрим су янында —
Аккош кебек бүген мин!
Ничек инде буялыйм да,
Ничек инде җебим мин...





Кинәт яңгыр басты безне.
Бик тиз килеп җитте ул.
Безнең аяк астыбызны
Нәни күлләр итте ул.





Шул күлләргә китте кереп
Әлфия дә, Әхәт тә.
Җылы яңгыр суын ерып
Йөрүләре рәхәт тә!



Бер керә алар, бер чыга:
— Әй яңгыр, шәп иттең! — дип.
Шулар артыннан бер суга
Мин дә кереп киттем бит.



Чупырдыйм мин нәни күлдә,
Су ерам тубыктан мин.
Нәрсә икәнен өстемдә
Бөтенләй онытканмын.



Ничек шуны күрмәгәнмен!
Күтәрелеп карасам —
Ап-ак дигән күлмәгемнең
Бөтен җире кара тап...





Нишләргә инде, нишләргә,
Әни миңа ни дияр?
Аяз булса да иртәгә,
Кара күлмәк ки, дияр.

Җилләтәм дә күлмәгемне,
Сыккан булып та карыйм,
Сөртә-сөртә күзләремне
Һаман болытка карыйм:

— Әй тагын яңгыр килмәсме,
Әй яңгыр килсен иде,
Үзе пычраткан күлмәкне
Юып та бирсен иде!..



МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

*Нуретдинов Заки Шарафутдинович*

ПУСТЬ БЫ ДОЖДИК ЛИЛ

СТИХ

(на татарском языке)

Редакторы *Р. Н. Даутов*

Художнигы *С. М. Кульбака*

Художество редакторы *Б. М. Альменов*

Техник редакторы *З. А. Ибраһимова*

Корректоры *А. Ш. Зарипова*

Производствога бирелде 20/VIII-1961 ел. Басарга кул куелды 7/II-1962 ел.
Кәгазь форматы 70×92$^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табагы 1. Басма табак 1(1,17).
Тираж 25 000 экз. Заказ № 1212. Бәясе 7 тиен.

Татарстан Культура министрлыгы каршындагы нәшрият һәм полиграфия промышленносте идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19. 1962 ел.